| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2018 елның 14 декабре | № 36 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 26 октябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 30 маендагы 11 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 26 октябрендәге 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр (2017 елның 30 маендагы 11 номерлы үзгәрешләр белән) кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5 абзац белән тулыландырырга:

«-18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарны салым түләүдән азат итеп, ташламаны бирергә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.1 Салым түләүчеләр - салым ташламалары хокукына ия физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калуы рәвешендә салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым органында булмаганда, шул исәптән салым түләүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта, салым органы салым ташламасы бирү турында гаризада күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым түләүченең салым ташламасына

салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы белешмәләрне шул белешмәләре булган органнардан, оешмалардан, вазыйфаи затлардан соратып ала.

Салым органының салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслый торган белешмәләр бирү турындагы запросын алган зат аны алганнан соң җиде көн эчендә яисә шул ук вакытта таләпне үтәмәү сәбәпләре турында салым органына хәбәр итә.

Салым органы күрсәтелгән хәбәр алынганнан соң өч көн эчендә салым түләүчегә әлеге салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләрнең запросы буенча алынмавы һәм салым түләүченең салым органына документларын тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итәргә тиеш».

2. Әлеге карарны Туктар-Урдаласыавыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе М.М.Җиһаншин